**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 10 апрелендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында гыйбадәт йорты янында элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 09 сәгать 00 минутка билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге составына керүче Иске Иглай авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 21.11.2023 ел 1 карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авыл җирлегендә гражданнар Җыенының 21.11.2023 ел, № 2 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. «2024 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр

инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 2600 сум күләмендә үзара салым кертүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп ризамы?:

- Иске Иглай торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.2. «Сууткәргеч төзү, халыкны эчәр су белән тәэмин итү өчен җыелган 2022 елгы гражданнарның үзара салым акчаларының калдыгын 80000 (сиксән мең) сум 00 тиен һәм республика акчаларын 321411 (өч йөз егерме бер мең дүрт йөз унбер) сум 05 тиен түбәндәге эшләргә кулланырга ризамы: су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау һәм су чыгару, су күтәрү манаралары, скважиналар һәм башка инженерлык корылмалары, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә.»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев